**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **БОЕРЫК**

21.03.2023 № 2

Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге территориясендә кулланылган терекөмөшле лампаларны туплау урыны турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган, яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә кулланылучы һәм тиешле җыймау, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру аркасында гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү калдыклары белән эш итү Кагыйдәләре нигезендә, (алга таба - Кагыйдәләр) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кулланылган терегөмөшле лампаларны туплау урыннарын шул исәптән мондый туплану урыннарын оештыру Кагыйдәләрнең 5 пункты нигезендә күпфатирлы йортларда туплану урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракта, әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Кулланучыларга туплану урыннары турында мәгълүмат бирү түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендлары аша башкарыла:

Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Фома авылы, Совет урамы, 19нчы йорт

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм httr://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш. http://nurlat.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Һ.Абдрахманов

Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башкарма
комитетының 2023 елның 21
мартындагы 2 номерлы карарына
кушымта

**Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны туплау урыны**

| N т/с | Бина | Адрес |
|---|---|---|
| 1 | Авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы | Татарстан Республикасы, Нурлат районы,<br>Фома ав., Совет ур., 19нчы й.<br>(тел.8-84345-3-52-61) |